КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 30 сентябрь г.Казань № 882

2019 елның 1 октябреннән 2021 елның 31 декабренә кадәрге чорга күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча төбәк программасының финанс тотрыклылыгын тәэмин итү чаралары планын («юл картасы»н) раслау турында

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының Россия Федерациясе субъектларында күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча төбәк программасын тормышка ашыру мәсьәләсе буенча бөтенроссия селектор киңәшмәсенең 2018 елның 11 декабрендәге 691-ПРМ-НС номерлы беркетмәсенең II бүлегендәге 4 нче пунктын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2019 елның 1 октябреннән 2021 елның 31 декабренә кадәрге чорга күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча төбәк программасының финанс тотрыклылыгын тәэмин итү чаралары планын («юл картасы»н) расларга.
2. Татарстан Республикасы министрлыкларына, кызыксынучы оешмалар белән берлектә, «юл картасы» чараларын тормышка ашыруны һәм хисап чорыннан соң килүче айның 15енә кадәр әлеге чараларны тормышка ашыруның барышы турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына кертүне тәэмин итәргә.
3. Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына хисап аеннан соң килүче айның 25енә кадәр әлеге чараларны тормышка ашыруның барышы турындагы җыелма хисапны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.
4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин